**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2020 пгт. Рыбная Слобода № 64пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 июнендәге 150пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сату-алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2017 елның 31 декабрендәге 504-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 июнендәге 150пи номерлы карары белән расланган» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру Кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 2 февралендәге 53пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3 өлешнең «л» пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 3 өлешнең «м» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «әлеге Федераль законда каралган контрактны үтәүгә, үзгәртүгә, шулай ук контракт шартларын үтәүгә, шул исәптән куелган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килү-килмәве өлешендә».

1.3) 3 өлешнең «н» пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Муниципаль заказ хезмәте» муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Җитәкче Р. Л. Исланов